СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Әгерҗе шәһәре № 10-8

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне (күмүне) оештыру һәм эшкәртүне оештыру турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 ст. 1 өлешенең 14 п., 48 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы»ның 3 пунктының “д” п., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 ст. 1 өлешендә 14 п., Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2021 елның 26 маендагы 02-06-2021 номерлы «Законга каршы килә торган хокукый акт»ка протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне (күмүне) оештыру һәм эшкәртү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 19 декабрендәге 20-4 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне (күмүне) оештыру һәм эшкәртү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 17 октябрендәге 30-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев